КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 декабрь г.Казань № 1269

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 июль, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 278 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1156 нчы; 2019 ел, 29 гыйнвар, 52 нче; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2019 ел, 13 июнь, 492 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 815 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 866 нчы; 2019 ел, 30 сентябрь, 883 нче; 2020 ел, 24 февраль, 132 нче; 2020 ел, 17 апрель, 300 нче; 2020 ел, 27 август, 747 нче; 2021 ел, 28 июнь, 509 нчы; 2021 ел, 25 август, 781 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (01.08.01*);»;

4.1 пунктта:

4.1.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.7. Электр энергетикасында дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.1.9 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктның 4.2.10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.10. Җылылык белән тәэмин итү тармагында бәяләрне (тарифларны) җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.3.5 пунктча өстәргә:

«4.3.5. Газ белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) билгеләүгә һәм (яки) куллануга төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.4 пунктта:

4.4.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.7. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә тарифларны җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.4.12 пунктчада «, шулай ук әлеге инвестиция программаларын тормышка ашыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.5 пунктның 4.5.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү тармагында тарифларны җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.6 пунктның 4.6.10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.10. Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм диагностика картасы дубликатын кәгазьдә биргән өчен түләү күләмнәрен саклап тотуга төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.7 пунктта:

4.7.8 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.7.13 пунктча өстәргә:

«4.7.13. Тормыш өчен кирәкле һәм иң мөһим дарулар исемлегенә кертелгән даруларга бәяләрне куллануга төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

4.8 пунктта:

4.8.17 – 4.8.19 пунктчаларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.8.29 – 4.8.31 пунктчалар өстәргә:

«4.8.29. Табигый монополияләр тармакларында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.

4.8.30. Россия Федерациясенең эчке базарында Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары тарафыннан бәяләре (тарифлары) дәүләт тарафыннан җайга салына торган җитештерү-техник билгеләнештәге продукцияләр, халык кулланышындагы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлегендә каралган продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.

4.8.31. Транспорт, тәэмин итү-сату һәм сәүдә оешмалары хезмәтләре исемлегендә каралган, алар өчен Россия Федерациясе субъектларының башкарма

хакимият органнарына тарифларны һәм өстәмә түләүләрне дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә кертү хокукы бирелә торган хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

6.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү һәм Дәүләт комитетының бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы карарлары проектларын әзерләгәндә һәм килештергәндә барлыкка килгән мәсьәләләрне хәл итү максатларында Фикер каршылыкларын карап тикшерү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссия составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы органнары, иҗтимагый оешмалар һәм федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары җитәкчеләренең тәкъдимнәре нигезендә Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу тармаклары буенча билгеләнә.

Комиссия эшчәнлегенең тәртибе (утырышлар үткәрү тәртибен кертеп) Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин